РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН
ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ
АЛЬКЕЕВСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
422870, С.Базарные Матаки,
ул.С.Крайнова,д.56

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ӘЛКИ
МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ
БАШКАРМА КОМИТЕТЫ
422870, ТР Базарлы Матак авылы,
С.Крайнов ур.,56

Телефон: (84346) 20-0-26, факс: (84346) 21-7-60. E-mail: alkay@tatar.ru, сайт: www.alkeevskiy.tatarstan.ru.

# ПОСТАНОВЛЕНИЕ

# КАРАРЫ

2020 елның 1 сентябре

314№

Әлки муниципаль районы Башкарма комитетының 2019 елның 22 августындагы «Бердәм дәүләт системасының территориаль ярдәмче системасы оешмасы, составы, көч һәм чараларның эшчәнлек тәртибе һәм гадәттән тыш хәлләрне кисәтү һәм бетерү турында»гы 297 номерлы карарына үзгәрешләр кертү турында

1994 елның 21 декабрендәге “Халыкны һәм территорияләрне табигый һәм техноген характердагы гадәттән тыш хәлләрдән яклау турында"гы 68-ФЗ номерлы Федераль законны үтәү йөзеннән, Россия Федерациясе Хөкүмәтенең 2003 елның 30 декабрендәге “Гадәттән тыш дәге хәлләрне кисәтү һәм бетерү буенча бердәм дәүләт системасы турында"гы 794 номерлы карары, Россия Федерациясе Хөкүмәтенең 2019 елның 28 декабрендәге «Россия Федерациясе Хөкүмәтенең кайбер актларына үзгәрешләр кертү һәм Россия Федерациясе Хөкүмәтенең кайбер актларының үз көчләрен югалтуын тану турында»гы 1934 номерлы карары нигезендә һәм Татарстан Республикасы Гадәттән тыш хәлләрне кисәтү һәм бетерү буенча территориаль ярдәмче системасының Әлки звеносы эшчәнлеген камилләштерү максатларында, Әлки муниципаль районы Башкарма комитеты

**КАРАР ИТӘ:**

1. Әлки муниципаль районы Башкарма комитетының 2019 елның 22 августындагы «Татарстан Республикасының Әлки муниципаль районында гадәттән тыш хәлләрне кисәтү һәм бетерү буенча территориаль ярдәмче системасының муниципаль звеносы турында»гы 297 номерлы карарына түбәндәге үзгәрешләр кертергә:

- Әлки муниципаль районының гадәттән тыш хәлләрне кисәтү һәм бетерү буенча территориаль ярдәмче системасының Әлки звеносы турында Нигезләмәнең (алга таба-Нигезләмә) 2 пунктында «халыкны һәм территорияләрне гадәттән тыш хәлләрдән яклау өлкәсендә» сүзләрен «халыкны һәм территорияләрне гадәттән

тыш хәлләрдән яклау, шул исәптән су объектларында кешеләр иминлеген тәэмин итү буенча» сүзләренә алмаштырырга;

- Нигезләмәнең 3 п. 4 абзацын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«объектив дәрәҗәдә - вәкаләтләренә халыкны һәм территорияләрне гадәттән тыш хәлләрдән яклау, шул исәптән су объектларында кешеләр иминлеген тәэмин итү буенча да мәсьәләләрен хәл итү кергән гадәттән тыш хәлләрне кисәтү һәм бетерү һәм оешмаларның янгын куркынычсызлыгын тәэмин итү комиссияләре.»

Нигезләмәнең 2 пунктындагы 2 абзацына «Әлки муниципаль районының Гражданлык яклау идарәсе» МКУ базасында төзелгән» сүзләрен өстәргә;

- Нигезләмәнең 3 пунктындагы 3 абзацын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

-«гадәттән тыш хәлләрне бетерү һәм янгыннарны сүндерүне оештыру вакытында авария-коткару һәм кичектергесез эшләр башкарганда –«Әлки муниципаль районының Гражданлык яклау идарәсе» МКУ»;

Нигезләмәнең 12 пунктын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«12. Авария-коткару хезмәтләре һәм авария-коткару формированиеләре эшчәнлеген координацияләүне ТР буенча Россия ГТХМ БИ ФЯКХ ДЯКХ 7 ЯХО 105 ЯКХБ башкара.

Нигезләмәнең 15 пунктындагы 2 абзацын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«Гадәттән тыш хәлләрдән саклау өлкәсендә халыкны әзерләү буенча методик җитәкчелек, координация һәм тикшереп торуны Татарстан Республикасы Гражданнар оборонасы эшләре һәм гадәттән тыш хәлләр министрлыгы һәм ТР буенча Россия ГТХМ БИ ФЯКХ ДЯКХ 7 ЯХО 105 ЯКХБ гамәлгә ашыра.»;

- 1 нче кушымтаның 1 пунктын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«ТР буенча Россия ГТХМ БИ ФЯКХ ДЯКХ 7 ЯХО 105 ЯКХБ»

- 1 нче кушымтаның 13 пунктында «Әлкиурман» ДБУ» сүзләрен «Әлки урман хуҗалыгы» ДБУ» сүзләренә алмаштырырга;

- 1 нче кушымтаның 10 пунктында «Кызыл Шәрыкъ АГРО» Ачык Акционер Җәмгыяте » сүзләрен «Кызыл Шәрыкъ Агро» АҖ» сүзләренә алмаштырырга;

-«1 нче кушымтаның Әлки МР 10 ИЯСХ» бүлегендә «Алькилес ИЯСХ» сүзләрен «Әлки урман хуҗалыгы ИЯСХ» сүзләренә алмаштырырга;

-2 нче Кушымтаның «Татарстан Республикасы буенча федераль янгынга каршы хезмәтнең 105 янгын часте» федераль дәүләт казна учреждениесе (килешү буенча)» бүлеген түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«Татарстан Республикасы буенча Россия ГТХМ Баш идарәсенең Федераль янгынга каршы хезмәтнең 7 нче янгын сүндерү һәм коткару отрядының 105 нче янгын сүндерү һәм коткару бүлеге(килешү буенча)»;

- «2 нче Кушымтаның Татарстан Республикасы Авыл хуҗалыгы һәм азык-төлек министрлыгының Әлки муниципаль районындагы авыл хуҗалыгы һәм азык-төлек идарәсе "Кызыл Шәрыкъ АГРО" ачык акционерлык җәмгыятенең Әлки филиалы (килешү буенча) бүлегендә «Кызыл Шәрыкъ АГРО» Ачык Акционер Җәмгыяте» сүзләрен «Кызыл Шәрыкъ Агро» АҖ» сүзләренә алмаштырырга;

- «2 нче Кушымтаның «Әлки урманчылыгы» ДКУ, «Әлкиурман» ДБУ» (килешү буенча) бүлегендә «Әлкиурман» ДБУ» сүзләрен «Әлки урман хуҗалыгы» ДБУ» «сүзләренә алмаштырырга.

2. Әлеге карарны Татарстан Республикасы Әлки муниципаль районының рәсми сайтында һәм Интернет мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендәге Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында урнаштырырга.

3. Карар рәсми басылып чыккан (халыкка җиткерелгән) көненнән үз көченә керә.

5.Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны үз өстемдә калдырам.

ТР Әлки муниципаль районы
Башкарма комитет җитәкчесе: И. В. Юсупов